**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

# КАРАР

29.03.2022 № 119

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 2019 елның 21 октябрендәге 165 номерлы карары белән расланган яңа редакциядә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 нчы ноябрендәге (2022 елның 14 мартына үзгәрешләр белән) 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә районы Советы

карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 2019 елның 21 октябрендәге 165 номерлы карары белән расланган, яңа редакциядә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә кушымтада бирелгәнчә үзгәрешләр кертергә .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының бюджет, финанс, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов

Әтнә район Советының
2022ел 29 мартындагы
119 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 2019 елның 21 октябрендәге 165 номерлы карары белән расланган, яңа редакциядә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр

1. 6 нчы маддәдә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы абзац өстәргә:
«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унынчы - унөченче абзацларны унберенче - ундүртенче абзацлар дип санарга;

2. 12.1 нче маддәдә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унҗиденче абзац өстәргә:

«бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача дәрәҗәле заемщиклар төркеменә әлеге Кодекс нигезендә кертелгән муниципаль берәмлек бюджетының хисап финанс елында үтәү барышында бюджет ассигнованиеләрен тиешенчә файдаланмауга бәйле барлыкка килгән калдыклар арасындагы аермадан артмаган күләмдә һәм әлеге өлешнең икенче абзацында каралган бюджет ассигнованиеләрен арттыру суммасында бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль берәмлек вәкиллекле органының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кулланыла;»;

б) унҗиденче-егерменче абзацларны унсигезенче-егерме беренче абзацлар дип санарга

3. 13 маддәнең 23 абзацын «Район,» сүзләреннән соң «муниципаль мөлкәт белән идарә иткәндә һәм (яисә) аннан файдаланганда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының керемнәрен һәм чыгымнарын булдыру,» сүзләрен өстәргә;

4. 17 маддәнең 2 өлешендә «Район,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган өлеше,» сүзләрен өстәргә;

5. 17 маддәнең 3 өлешендә «Районның бурыч йөкләмәләрен каплау күләмнәрен» сүзләреннән соң, “моңа инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләме керми» сүзләрен өстәргә;